**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә җаваплар (муниципаль тур, 2018-2019 уку елы) 7 нче сыйныф**

**Максималь балл – 40 балл**

**I. Әдәбият теориясенә караган биремнәр (12 балл).**

**1.** Поэма жанрына хас үзенчәлекләрне Һ. Такташның “Мокамай” поэмасы мисалында аңлатыгыз (10 балл). **Хикәяләү сыйфаты бар, вакыйгалар хс-кичереш белән үрелеп бара, лирик әсәрләргә хас ритм, интонация саклана һ.б.**

2. Поэма кем исеменнән сөйләнелә? Бер сүз яки сүзтезмә белән язып куегыз (2 балл). **Лирик герой**

**II. Әдәби иҗатка караган биремнәр (18 балл).**

1. Чистай районы Яуширмә авылы – Чистай – Орнебург- Берлин – Анкара – Истанбул. Әлеге урыннар кайсы әдип исеме белән бәйләнгән? (3 балл) **Г.Исхакый**

2. Бу әдип әдәбиятның кайсы төрләрендә иҗат итә? Бер җөмлә белән язып куегыз (3 балл). **Г.Исхакый проза һәм драматургия төрләрендә эшли.**

3. Г.Исхакыйның “Җан Баевич” әсәрендә автор нинди сыйфатлардан көлә? (6 балл) **үз кыйбласын югалткан, хәтта үз милләтеннән йөз чөергән сәүдәгәрләрдән көлә**.

4. Әлеге әсәрдә Шакирҗанга хас сыйфатларны капма-каршы ике төркемгә – уңай һәм тискәре сыйфатларга бүлеп языгыз (6 балл).

**III. Иҗади эш (10 балл).**

Түбәндәге сүзләрне танылган шагыйрьнең әсәреннән бер строфалык шигырь итеп формалаштырыгыз: *ыштансыз, белән, әкияттәге, үрмәләп, кебек, идек, бергәләп, каен, ике, танышып, бала, дөнья, башларына, ике, йөргән, малай.*

**Әкияттәге ике бала кебек,**
**Каен башларына үрмәләп,**
**Ике ыштансыз малай дөнья белән**
**Танышып йөргән идек бергәләп (Һ.Такташ)**

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә җаваплар (муниципаль тур, 2018-2019 уку елы) 8 нче сыйныф**

**Максималь балл – 42 балл**

**IV. Әдәбият теориясенә караган биремнәр (12 балл).**

**3.** Трагедия жанрына хас үзенчәлекләрне Ф.Бурнашның “Таһир-Зөһрә” әсәре мисалында аңлатыгыз (10 балл). **Геройлар үзләреннән күпкә көчле сыйфатлар белән каршылыкка керә, әсәр үлем белән тәмамлана, ул үлем үкенечле кабул ителә, трагик пафос өстенлек итә һ.б.**

**4.** Әсәрдәге Таһир белән Зөһрәгә бәйле вакыйгалар ничек тәмамлана? Бер сүз яки сүзтезмә белән язып куегыз (2 балл). **Вакыйгалар Таһир белән Зөһрәнең үлеме белән тәмамлана.**

**V. Әдәби иҗатка караган биремнәр (20 балл).**

1. Пенза өлкәсе Аккүл авылы – Казан – Орнебург – Ташкент. Әлеге урыннар кайсы әдип исеме белән бәйләнгән? (3 балл) **К.Тинчурин**

2. Бу әдип әдәбиятның кайсы төрләрендә иҗат итә? Бер җөмлә белән язып куегыз (3 балл) **К.Тинчурин проза һәм драматургия өлкәләрендә иҗат итә.**

3. К.Тинчуринның “Сүнгән йолдызлар” әсәрендә автор нинди сыйфатларны фаҗига итеп күтәрә? (4 балл) **Мәхәббәтне югалту, акылны югалту, тормыш авырлыклары алдында югалып калу, җавапсыз мәхәббәт һ.б.**

4. Әлеге әсәрдә Исмәгыйль күргән төш символик мәгънәгә ия, аны әсәр сюжеты белән бәйләп аңлатыгыз (10 балл). **Йолдыз, төн, кан, аждаһа Исмәгыйль, Сәрвәр, мәхдүм, авыл егетләренең сугыш чыкканнан соңгы язмышын алдан хәбәр итә.**

**VI. Иҗади эш (10 балл).**

Түбәндәге сүзләрне танылган шагыйрьнең әсәреннән бер строфалык шигырь итеп формалаштырыгыз: *усал, үзе, шикелле, матур, кебек, үзе, дә, сөйкемле, бер, үзе, түгел, үзе, болай, усал.*

*Үзе матур,*
*Үзе сөйкемле,*
*Үзе усал,*
*Үзе болай бер дә*
*Усал түгел кебек шикелле.*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә җаваплар (муниципаль тур, 2018-2019 уку елы) 9 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 48 балл**

**VII. Әдәбият теориясенә караган биремнәр (12 балл).**

**5.** Хикмәт жанрына хас үзенчәлекләрне М.Колый хикмәтләре мисалында аңлатыгыз (10 балл). **Кыскалык, төп фәлсәфи фикерне дүрт юлга сыйдыру, нәсихәт бирү, хикмәтле фикер әйтү һ.б.**

**6.** Хикмәтләр кем исеменнән сөйләнелә? Бер сүз яки сүзтезмә белән язып куегыз (2 балл). **Суфый яки лирик герой**

**VIII. Әдәби иҗатка караган биремнәр (26 балл).**

1. Чирмешән районы Яңа Кади авылы – Каргалы – Бохара – Сәмәрканд – Чистай өязе Исләй авылы. Әлеге урыннар кайсы әдип исеме белән бәйләнгән? (3 балл) **Габдерәхим Утыз Имәни**

2. Бу әдип әдәбиятның кайсы төрендә иҗат итә? Бер җөмлә белән язып куегыз (3 балл) **Габдерәхим Утыз Имәни әдәбиятның поэтик төрендә иҗат итә.**

3. Габдерәхим Утыз Имәнинең лирик героена нинди сыйфатлар хас? (10 балл) **Үгет-нәсихәт бирә, белемлелекне югары күтәрә, тәнкыйтьләү сыйфаты көчле һ.б.**

4. Аның әсәрләрендә мәгърифәткә бәйле нинди фикерләр урын ала? (10 балл). **Халыкны аң-белемгә өнди, зиһенен баетырга чакыра, укымышлы кешеләрне мактый һ.б.**

**IX. Иҗади эш (10 балл).**

Түбәндәге сүзләрне танылган шагыйрьнең әсәреннән бер строфалык шигырь итеп формалаштырыгыз: *яуды, имди, кебек, энҗе-мәрҗән, итәгемә, мин, җыйдым, җиргә, яңгыр, аларны*.

*Энҗе-мәрҗән яуды җиргә яңгыр кебек,* -
*Мин аларны итәгемә җыйдым имди.*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә җаваплар (муниципаль тур, 2018-2019 уку елы) 10 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 48 балл**

**X. Әдәбият теориясенә караган биремнәр (12 балл).**

1. Фәлсәфи шигырьгә хас үзенчәлекләрне Дәрдемәнд иҗаты мисалында аңлатыгыз (10 балл). *Яшәү, үлем, яшәү мәгънәсе турында уйлана, шартлылык көчле, лирик герое философ, яшәү кыйммәтләре турында уйлый һ.б.*

2. Аның шигырьләре кем исеменнән сөйләнелә? Бер сүз яки сүзтезмә белән язып куегыз (2 балл). *Лирик герой*

**XI. Әдәби иҗатка караган биремнәр (26 балл).**

1. Оренбург өлкәсе Акман авылы – Казан – Әстерхан – Уфа. Әлеге

урыннар кайсы әдип исеме белән бәйләнгән? (3 балл) **С.Рәмиев.**

2. Бу әдип әдәбиятның кайсы төрләрендә иҗат итә? Бер җөмлә белән язып куегыз (3 балл) **С.Рәмиев проза, поэзия, драматургия өлкәләрендә иҗат итә.**

3. С.Рәмиевнең лирик героена нинди сыйфатлар хас? (10 балл) **Гыйсъянчы, бунтарь холыклы, дөньяны үзгәртү теләге белән яна, бөтен әйбергә каршы чыга, бөтен төрле кыйммәтләрне кире кага һ.б.**

4. С.Рәмиевнең әсәрләрендә үз чорына хас нинди фикерләр урын ала? (10 балл). **Татар халкын азатлыкка, мәгърифәткә өнди, иҗтимагый тәртипләрне тәнкыйтьли, милли проблема көчле һ.б.**

**XII. Иҗади эш (10 балл).**

Түбәндәге сүзләрне танылган шагыйрьнең әсәреннән бер строфалык шигырь итеп формалаштырыгыз: *йоклый, уянам, кебек, таң, бер, уйланам, вакыты, тиле, татар, мин, уянам, тик, йокысыз, да, үзем*.

***Таң вакыты... Татар йоклый...***
***Мин, йокысыз, уянам,***
***Уянам да, тиле кебек,***
***Тик бер үзем уйланам.***

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә җаваплар (муниципаль тур, 2018-2019 уку елы) 11 нче сыйныф**

**Максималь балл – 48 балл**

**XIII. Әдәбият теориясенә караган биремнәр (12 балл).**

1. Повесть жанрына хас үзенчәлекләрне А.Гыйләҗевның “Әтәч менгән читәнгә” әсәре мисалында аңлатыгыз (10 балл).

2. Әсәрдә дуслыкны, яшәү кыйммәтләрен чагылдырган символик образны язып куегыз (2 балл). **Әтәч**

**XIV. Әдәби иҗатка караган биремнәр (26 балл).**

**1.** Аксубай районы Иске Кармәт авылы – Тобол губернасы – Уфа – Казан – Покровка. Әлеге урыннар кайсы әдип исеме белән бәйләнгән? (3 балл) **Х.Туфан**

2. Бу әдип әдәбиятның кайсы төрендә иҗат итә? Бер җөмлә белән язып куегыз (3 балл) **Лирика, лиро-эпика / Поэзия**

3. Х.Туфанның лирик героена нинди сыйфатлар хас? (10 балл) **Уйчан, лирик холыклы, фаҗигале, тормышның асылын аңлый, әмма үзгәртә алмый, авырлыклар алдында югалып калмый торган көчле рухлы һ.б.**

4. Х.Туфанның иҗатына үз чорына хас нинди сыйфатлар хас? (10 балл).

**Тнкыйди фикер көчле, символик образлар ярдәмендә үз фикерен җиткерә, эзоп теле алымына һәрвакыт мөрәҗәгать итә, сугыш турында, тормышның авырлыгы турында күп яза һ.б.**

**XV. Иҗади эш (10 балл).**

Түбәндәге сүзләрне танылган шагыйрьнең әсәреннән бер строфалык шигырь итеп формалаштырыгыз: *иде, сары, күңелсез, иде, көз, каеннар, кыраулы, иде, җирнең, астралар, шушындый, гөлләр, чагы*.

***Көз иде... Җирнең шушындый***
***Күңелсез чагы иде;***
***Астралар, гөлләр кыраулы,***
***Каеннар сары иде...***